ТАТЛЫ АЗЫК

Татарстан кырларында шикәр чөгендерен җыю дәвам итә

> 2

КИМ ТҮГЕЛЛӘР!

Авыру балаларның күбесе өйдә түгел, мәктәптә укый хәзер

> 3

ХӘЛ БЕЛЕШҮ

Үзебезнең ничек үзгәргәнебезне үзебез дә сизми калдык бугай

> 3



ХӘЕРЛЕ КӨН!

Казанда Зөлфәт Хәкимнең шушы исемдәге икенче концерты узды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 141 (28914) | Сишәмбе | 27 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Социаль яклау

БЕР ТҮЛӘҮДӘ

РОССИЯДӘ УНИВЕРСАЛЬ ПОСОБИЕ ГАМӘЛГӘ КЕРӘЧӘК

Киләсе елның 1 гыйнварыннан Россиядә аз керемле гаиләләр өчен универсаль пособие гамәлгә керәчәк. Ул балалы гаиләләргә моңа кадәр түләнгән барлык төр пособиеләрне берләштерәчәк. Яңа пособие кертелү турында хәбәр таралу белән күпләр: «Бүген баласына дәүләттән пособие алган кешеләргә өстәмә тагын бер түләү бирелә башлый икән», – дип сөенде. Бу дөрес түгел.

– Моңа кадәр пособие алган кешеләр киләсе елдан берьюлы ике төрле пособие алачак икән, дип уйлаучылар ялгыша. Яңа кертеләчәк универсаль пособие – бүген гамәлдә булган 3 яшькә кадәр, 3–7 яшь, 8–17 яшьлек балаларга түләнә торган барлык пособиеләрне үз эченә алачак. Гаиләдәге бала киләсе елның 1 гыйнварына кадәр туган булса, ата-ана пособие алуның ике юлын сайлый ала. Аны элеккеге кагыйдәләр буенча алыргамы, әллә инде беренче көннән үк универсаль пособие итеп рәсмиләштерергәме? Моны ата-ана үзе хәл итәчәк. Яңа төр пособие йөклелекнең иртә срокларында исәпкә баскан мохтаҗ хатын-кызларга да билгеләнәчәк, – дип ачыклык керттеләр Россия Пенсия фондының Татарстан буенча идарәсендә «ВТ» соравына.

Пособие күләме төбәктәге яшәү минимумының 50, 75 яисә 100 процент күләмен тәшкил итәчәк. Шул рәвешле, универсаль пособиенең уртача күләме 7 мең, 10,5 мең, 14 мең тәшкил итәчәк. Бу максатка дәүләттән 1,7 трлн сум акча бүлеп биреләчәк. Универсаль пособиене якынча 10 млн балага түләргә планлаштыралар.

Универсаль пособиене алу өчен бер генә гариза тапшырырга кирәк булачак. Аны дистанцион рәвештә – Дәүләт хезмәтләре порталы (www.gosuslugi.ru) аша да, күпфункцияле үзәккә яки социаль иминият фондына шәхсән барып та тутырырга мөмкин. Баланың әлеге төр пособиене алырга мохтаҗмы-түгелме икәнен ачыклаганда белгечләр

Илдар Мөхәммәтҗанов

гаиләнең соңгы бер елдагы керемнәренә игътибар итәчәк. Бу чорны гариза тапшыру көненнән дүрт ай алдан исәпли башлыйлар. Пособиегә мохтаҗлыкны тикшергәндә айлык хезмәт хакын, эшмәкәрлектән кергән табышны гына түгел, пенсия, стипендия, милек, торак саткан, арендага биргәннән кергән акча, кертем буенча процентлар да исәпкә алыначак.

Быелның 1 апреленнән законга кертелгән төзәтмәләр нигезендә хәзер пособие билгеләгәндә гаиләнең лотереяда откан, тотализатор, комарлы уеннардан алган табышы да исәпкә алыначак. Эшмәкәрлекләргә ярдәм йөзеннән бирелгән грант һәм субсидияләр, ана капиталы, салым вычеты, гаиләгә мәрхүмне җирләү өчен бирелгән социаль пособие акчалары исә универсаль пособие билгеләгәндә исәпкә алынмый.

Казанның Кадыш бистәсендә яшәүче өч бала әнисе Алсу Гатауллина яңалыкны шатланып кабул иткән. Бер төрле пособиене алып бетергәч, икенчесен яңадан рәсмиләштереп мәшәкатьләнәсе булмаячак, янәсе. Бер тапкыр рәсмиләштерәсең дә, вәссәлам! Әмма аны билгеләгәндә нәрсәләрнең исәпкә алынуы белән танышкач, универсаль пособиене рәсмиләштерү бик отышлы булмаячак икән дигән нәтиҗәгә килгән Алсу.

– Балаларга хәзер түләнгән пособиеләрне билгеләгәндә гаиләнең банк кертемнәреннән алынган процентлары исәпкә алынмый иде. Универсаль пособие бирер алдыннан исә анысын да тикшерәчәкләр икән. Бу бит балага пособие алу ихтималы бермә-бер кими дигән сүз. Кулдагы банк карталарына кергән-чыккан акчаны да исәпкә алырга мөмкиннәр, диләр. Анысы да күңелемә ятмый. Әйтик, мин үзем безнең балалар бакчасында ата-аналар комитетында исәпләнәм. Балаларга кирәк-ярак аласы булганда, ата-аналар миңа акча күчерә. Кәгазьдә табыш алган кебек күренсәм дә, бу акча чынлыкта миңа түгел бит. Гаделсезлек килеп чыга, – ди Алсу.

Әмма рәсми документта соңгысы турында бер сүз дә юк. Сүз уңаеннан, киләсе елның 1 гыйнварыннан Россиядә яшәү минимумын – 14375 сумга, минималь хезмәт түләвен 16242 сумга җиткерергә җыеналар. Бу, үз чиратында, хезмәт хаклары белән социаль түләүләргә дә кагылачак. 1 гыйнвардан Россиядә пенсияләр дә 4,8 процентка артыр дип көтелә.

Ахыры 2 нче биттә >

Президент – Төрекмәнстанда

Рөстәм Миңнеханов Төрекмәнстанга эш сәфәре кыла. Бу ил җитәкчелеге чакыруы буенча ул Төрекмәнстан бәйсезлегенең 31 еллыгына багышланган чараларда катнаша.

Эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов Төрекмәнстан Президенты Сәрдәр Бердымөхәммәдов белән очрашты. Сәламләү сүзендә ул Төрекмәнстан халкының өч дистә ел эчендә социаль-икътисади үсештә зур уңышларга ирешүен билгеләп үтте.

«Сезнең ярдәмегез һәм безнең илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга юнәлдерелгән Татарстан – Төрекмәнстан хезмәттәшлеген үстерү мәсьәләләренә аерым игътибар бирүегез өчен тирән рәхмәтемне белдерәм», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты республиканың кайбер предприятиеләренең актив хезмәттәшлеген билгеләп үтте. Узган ел нәтиҗәләре буенча ике арадагы товар әйләнеше 77,5 миллион доллар тәшкил иткән. Очрашуда бу күрсәткечне арттыру кирәклеге турында фикер алыштылар. Аерым алганда, нефть чыгару, газ ташу, автомобиль, авиа-, суднолар төзү, химия продукциясе белән тәэмин итү һ.б. юнәлешләр буенча резервлар бар.

Октябрь ахырында Ашхабад һәм Мары шәһәрләрендә Төрекмәнстанда Татарстан мәдәнияте көннәре узачак. Аның кысасында Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар булачак. Рөстәм Миңнеханов Сәрдәр Төрекмәнстан Президентына бу илдә яшәүче татарларга игътибарлы булулары һәм ярдәм күрсәтүләре өчен аерым рәхмәт белдерде.

Акча алдан йөри

Россия Хөкүмәте Татарстанга торак төзү өчен акчаны алдан ук бернинди тоткарлыксыз бирәчәк. Безнең республикадан тыш, Карачай-Черкес, Чечня, Удмуртия, Краснодар крае, Кострома, Липецк һәм Самара өлкәләренә бу максаттан 6,3 миллиард сум юллана. Министрлар Кабинетының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, төбәкләрнең коммуналь инфраструктурасын яңартуга (йортларны төзекләндерү, су торбаларын алыштыруга һ.б.) барлыгы 11,1 миллиард сум биреләчәк.

2023–2024 елларда тотылырга тиешле бюджет акчасын субъектлар инде быел ук алачак.

Татарстан белән Лисичанск арасы

Луганск Халык Республикасының Лисичанск шәһәрендә Татарстан тапшырган мобиль сырхауханә эшли. Биредә УЗИ узарга, күз табибына, хирургка күренергә мөмкин. Республикадан килгән табиблар, кирәк булганда, операция дә ясый. Дәүләт Думасы депутаты, Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар комитеты әгъзасы Татьяна Ларионова «Татар-информ» хәбәрчесенә әйтүенчә, биредә Республика клиник хастаханәсе һәм Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсе табиблары балаларны да, олыларны да кабул итә. «Әлбәттә, Лисичанскида яшәүчеләргә медицина ярдәме бик кирәк. Алар җылылык бирелмәгән, гади генә уңайлыклары да булмаган йортларда яшәргә мәҗбүр. Шуңа күрә ОРВИ кебек чирләр белән еш авырыйлар», – дигән ул.

Күптән түгел генә Татьяна Ларионова республика делегациясе составында Луганск Халык Республикасында булып кайткан. Татарстанлылар Лисичанск халкына хәйрия ярдәме тапшырган. Барлыгы 6 йөк машинасына он, азык-төлек, дарулар, тәрәзәләр, су савытлары, хуҗалык кирәк-яраклары, шәмнәр, җылы киемнәр төяп китерелгән. Балаларга уку кирәк-яраклары тутырылган букчалар белән берәттән, физкультура дәресләре өчен спорт кирәк-яраклары да тапшырылган.

Һава торышы бозыла

Бу атнада Татарстанда яңгырлар көтелә, җиңелчә генә кырау төшәчәк. Якындагы көннәрдә, көнбатыштан циклон үтеп керү сәбәпле, явым-төшемле суык һава хөкем сөрәчәк. Чәршәмбе – 28 сентябрьдә көндез барлык районнарда диярлек яңгыр, секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил. Көндез һава температурасы +5…+10 градустан артмаячак. Төнге сәгатьләрдә 0…+5 градус, урыны белән кырау. Пәнҗешәмбе һәм җомга – 29–30 сентябрьдә дә болытлы, яңгырлы һава, көчле җил көтелә. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +5…+11, төнлә +2…+7 градус күрсәтәчәк.

Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразына караганда, шимбә – 1 октябрьдә, атмосфера басымы арту сәбәпле, явым-төшем акрынлап туктаячак. Көндез һава температурасы берникадәр күтәрелеп, +10…+15 градус тәшкил итәчәк.

Фаҗига

Канлы дүшәмбе

Күрше республикада – фаҗига. Ижау шәһәренең Пушкин урамындагы 88 нче мәктәбенә дәрес вакытында билгесез ир-ат класска кереп, ут ача. Соңгы мәгълүматлар буенча, фаҗигадә 15 кешенең гомере өзелә. Шуларның 11е – мәктәп укучылары. Араларында 7, 10, 11 һәм 15 яшьлекләре бар. Тагын 24 кеше төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Ут ачкан ир-ат соңрак үз-үзен үтерә...

Җинаять эше кузгатылды

Рәсми мәгълүматларга караганда, мәктәпкә үтеп кергән зат кара киемнән, балаклавадан була. Кергәндә үк ул каравылчыны үтерә. Шуннан соң мәктәп буенча китә. Күпчелек балалар һәм укытучылар кабинетларда бикләнергә өлгерә. Ул арада социаль челтәрләрдә балаларның мәктәп территориясеннән йөгереп чыгулары, махсус хезмәтләрнең килүләрен күрсәткән фото һәм видеоязмалары таралды. Балалар исә бикләнеп утырган җирләреннән фото һәм видеолар урнаштыра башлый…

Сәгать 11 тулып киткәч Удмуртия башлыгы Александр Бречалов мәктәпкә һөҗүм иткән кешенең үз-үзен үтерүе хакында хәбәр итте. Ул арада белем йортын тулысынча камап алып, эвакуация эшләре башкарыла иде.

Тикшерүләр күрсәткәнчә, җинаятьченең өс киеменә нацистлар символикасы төшерелгән була. Соңрак аның Артем Казанцев исемле кеше булуы ачыкланды. Ул 1988 елгы, элегрәк шушы мәктәптә укыган да. Тикшерүчеләр ул яшәгән 9 катлы йортта да тентү оештырган. Россия Гвардиясе матбугат хезмәте мәгълүматы буенча, мәктәпкә һөҗүм итүченең мәете янында хәрби патроннар, шулай ук буш һәм патроннар белән җиһазландырылган ике травматик пистолет табылган. Коралга ия кеше буларак Артем учетта тормаган. Аның каравы җинаятьченең психоневрологик диспансерда учетта торуы билгеле.

Удмуртиядә өч көнлек матәм көне игълан ителде. Фаҗигадә зыян күрүчеләрнең якыннарына психологик һәм матди ярдәм күрсәтеләчәк. Россия Җинаять кодексының ике маддәсе («Ике һәм аннан да күбрәк кеше үтерү» һәм «Законсыз корал сатып алу, саклау һәм йөртү») буенча эш кузгатылды.

Удмуртияне генә түгел, әлеге вакыйга бөтен илне тетрәндерде. Казан исә кабат узган елның канлы май аен искә алгандыр… Күршеләрнең кайгысын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та уртаклашты. «Мәрхәмәтсез һөҗүм нәтиҗәсендә балаларның гомере өзелүен аңлау авыр. Бу хәл Татарстан халкын зур кайгыга салды. Республика халкы исеменнән, шәхсән үз исемемнән вафат булганнарның гаиләләренең, туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклашам», – диелә аның Удмуртия башлыгы исеменә язылган телеграммасында.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Удмуртия Дәүләт Советы Рәисе Владимир Невоструев исеменә кайгы уртаклашу телеграммасы юллады. «Татарстан Дәүләт Советы депутатлары һәм шәхсән үз исемемнән Ижау шәһәренең 88 нче мәктәбендәге фаҗигагә бәйле рәвештә һәлак булучыларның якыннарының кайгысын уртаклашабыз. Мәктәпкә кораллы һөҗүм ясалу сәбәпле бер гаепсез кешеләрнең, балаларның һәлак булуы турындагы коточкыч хәбәр татарстанлыларны нык тетрәндерде. Һәлак булганнарның якыннары һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклашабыз. Зыян күрүчеләргә тизрәк савыгуларын телибез. Бу матәм көннәрендә сезнең белән бергә кайгырабыз», – диелә телеграммада.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Петр ТОЛСТОЙ, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары:

Ижау мәктәбендәге фаҗига балаларның һәм өлкәннәрнең гомерен өзде. Бу хәлләргә нокта кую өчен барысын да эшләргә кирәк. Барлык белем бирү оешмаларын район һәм шәһәрләрдән төбәк дәрәҗәсенә күчерергә кирәк. Бу балаларыбызның иминлеген һәм белем бирү сыйфатын арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Бу эш белән тиз арада шөгыльләнәчәкбез.

(«Парламентская газета»дан)

ЯЛДА ДА – ЭШ

«Аргументы и факты» газетасы ялда вакытта да эшкә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итәргә мәҗбүр булган һөнәр ияләрен барлаган. Сораштыруда катнашучыларның нибары 6 проценты ялында эшләүдән катгый баш тарта икән.





Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КИЕРЕНКЕЛЕК ШАРТЛАУГА КИТЕРМӘСМЕ?

Үткән атнада дөньякүләм киеренкелек үзенең моңарчы күрелмәгән ноктасына җитте. Тактик атом-төш коралы кулланылу ихтималлыгы бик нык көчәйде, стратегик ракеталар белән янаулар да сәясәт кырында зур хәвеф тудырдылар. «Российская газета» үзенең «Телеграм-канал»ына Америка җитәкчелегенең атом коралы кулланган очракта катастрофик нәтиҗәләргә китерәчәген әйтеп, Россия элитасын кисәтүе хакында язды. АКШ Президентының Милли куркынычсызлык буенча киңәшчесе Джейк Салливан «хәлиткеч җавап»ның шунда ук булачагын әйткән. Хәзер километр ярымлык радиуста гына зыян сала торган тактик бомбалар бар. Менә шуларның берничәсен шартлатып карау ихтималлыгы зур. Кремльдә шаярмауларын әйтәләр, океан артындагы Ак йортта да җавап бирергә тәвәккәллек җитәрлек дип белдерәләр. Хәл шуның белән катлаулы: кечкенә бомбалардан башланган эш стратегик коралларның хәрәкәтенә китерергә мөмкин. Бу исә планетакүләм катастрофаның котылгысызлыгына илтәчәк. Шимбәдән якшәмбегә каршы төндә американнар стратегик атом-төш ракеталарын күзәтүче самолетларын һавага күтәрделәр. Дөньядагы иң сирәк очрый торган һәм уникаль RC-135S «Cobra Ball» очкычларының икесе Аляска ягыннан Россия чикләренә якын килде. Берсе АКШ үзәгендә очып йөрде. Америкада бары тик өч кенә шундый самолет бар. Шахталардагы баллистик ракеталар урыннарыннан кузгала башлау белән, каршы як аларның кай тарафка очачагын тикшереп тормыйча җавап уты ачачак дигән сүз бу. Киеренкелекнең бу дәрәҗәгә җитүе бик начар, әлбәттә. Әмма ике якның да җитәкчелеге аек акылга өстенлек бирер дип фаразлыйбыз.

АКШ Конгрессының өлкән киңәшчесе Пол Массаро «Твиттер»да «Диктаторлар куркыныч астында» дип язып куйды. Сүзнең кайсы ил турында баруы аңлашылмый. Кытайда, имештер, хәрби түнтәрелеш бара дигән хәбәрләр чыкты. Илдә тимер юл һәм авиарейслар тукталды, зур күләмдә гаскәрләр Пекинга таба хәрәкәт итә, дип яздылар. Әмма бу фейк кына дип әйтүчеләр дә җитәрлек. Рәсми Мәскәү, мәсәлән, шулай дип тынычландыра.

Иранда исә инде берничә көн зур фетнә кыза. Фарсыларның дулап урамга чыгулары бик еш булып тора ул үзе. Вәләкин бу юлы бунт масштаблырак һәм озаккарак сузыла. Ул 22 яшьлек бер кызның әхлак полициясе тарафыннан тоткарланганнан соң үлүен сылтау итеп башланды һәм көннән-көн көчәя. Гыйсъянчылар полиция белән бәрелешкә керәләр, автомобильләр яна. Атна ахырында Иран революциясен саклаучылар корпусы куәтле репрессияләр башлады, дигәннәр иде. Әмма давыл һаман да тынмый. Үлүчеләр бар, аларның саны төрлечә атала. Вазгыять бик катлаулы һәм ярсуларның нинди нәтиҗәгә китерәсен әйтеп булмый. Иран әлеге вакытта Россиянең иң ышанычлы аркадашы, анда хәл үзгәрсә, Мәскәүнең эчке һәм тышкы сәясәтенә дә тәэсир ясаячак.

Россиядә

ИКЪТИСАДНЫҢ ЯҢА КОНТУРЛАРЫ

Россиянең эчке вазгыяте мобилизациягә бәйле рәвештә формалаша. 21 сентябрь көнне без көтмәгәндә яңа чынбарлыкка күчтек. Коралды көчләргә мәҗбүри чакыру халыкның кәефенә дә, икътисадка да, бюджетка да, социаль өлкәгә дә зур тәэсир ясый һәм ясаячак. Безнең газ экспортының кимүе эчке базардагы сыек ягулыкның бәясен күтәрер дигән фаразыбыз тормышка ашып килә. Хөкүмәт быелның 1 декабреннән ТКХ бәяләрен тагын бер тапкыр индексацияләячәк дигән хәбәрләр бар. Бәянең иң югары күтәрелү ноктасы итеп 9 процент алыныр, мөгаен. Федераль Икътисади үсеш министрлыгы 3 кешелек гаилә айга уртача 324 сумга артыграк түләячәк дип исәпләп куйган инде. Газ бәясендә кеше саны түгел, йортның квадрат метрлары зуррак роль уйный ләкин. Газ белән җылытылган өй булса инде. Кышкы түләүләр күләме байтак артачак һәм бездәге хезмәт хаклары белән югалтулар шактый ук сизеләчәк. Газ экспортының тагын да кимүе ихтимал, чөнки Көнбатышта «Газпромбанк»ны SWIFT системасыннан өзү турында сүз башладылар. Россиянең үз халыкара түләүләр системасына да халыкара басым көчәя. Төркия булып Төркия «Мир» карталарыннан баш тартыр, ахры. Дөрес, төрекләр ике ил өчен генә кулланыла торган түләү системасын гамәлгә кертмәкчеләр. Әрдоган Россия туристларын да югалтырга теләми, ике ил арасындагы сәүдә әйләнешен дә югарырак күтәрергә омтыла. Әнкара бартер сәүдәсенә күчү ихтималлыгын да таный. Төрекләрнең Иран белән бартер сәүдәсендә бай тәҗрибәсе бар. Мобилизация игълан ителгәч, Россиянең вазгыяти аркадашлары Кытай һәм Һиндстан да безнең чималны куллануны чикләргә җыенуларын белдерәләр. Пекин үз позициясен аңлатты инде: конфликтны тизрәк төгәлләргә һәм сөйләшүләр өстәле янына утырырга киңәш итте.

Вьетнам банкы BIDV һәм Казахстанның «Халык» банкы да Россиянең «Мир» карталарына банкоматлар аша да, терминаллар аша да хезмәт күрсәтүдән туктадылар.

Санкцияләр көчәйгән саен, Россия сумы ныгый. Хәтта нефть бәясенең түбәнәюе дә рубльнең тез астына суга алмый. Төп ставканы киметү дә файда бирми. Бу сумның каты валютага әйләнүен аңлатмый ләкин. Россиядә евро һәм долларлар файдасыз кәгазьгә әйләнәләр, алар белән берни дә эшли алмыйсың дигән сүз генә. Шуңа банклар алардан котылырга ашыга. Инвесторлар долларлардан гына түгел, кыйммәтле кәгазьләрдән дә котылалар соңгы көннәрдә. Аларны сатып, акчага әйләндерүне кулайрак күрәләр. Бу фонд базарындагы зур түнтәрелешкә китерде. Белгечләр яңа атнада сум ныгуын дәвам итәр, диләр. Эре компанияләр салымнарын һәм дивидендлар түләү өчен дә валюта саталар. Чоры шундый түләүләр вакыты. Сум курсының күтәрелүенә китерә монысы да. Бюджет өчен бер дә файдага түгел бу күтәрелеш. Оборона өчен өстәмә чыгымнар барлыкка килү дә бюджетның чыгым өлешен арттыра. Федераль хөкүмәт өч еллык бюджетны хуплады. 2023 елның керемнәре 26,1 триллион сум булыр дип көтелә, чыгымнар исә – 29 триллион. 2,9 триллион долларлык дефицитны эчке финанс базарыннан бурычка алырга туры киләчәк.

ИСӘН-САУ КҮРЕШИК!

Вазгыять

Илдә өлешчә мобилизация дәвам итә. Район һәм шәһәрләрдә егетләрне хәрби җыен узасы урыннарга озата башладылар. Аларны автобуска утыртып, артларыннан кулъяулык болгау белән генә эш бетми. Егетләрнең күңеле тыныч булсын өчен гаиләләренә ярдәм күрсәтәчәкләр. Барысы да гадел һәм дөрес булсын өчен дә чаралар күрергә туры киләчәк.

Чаллыда шимбә көнне 74 егетне озаттылар. Кала мэры Наил Мәһдиев әйтүенчә, өлешчә мобилизация шәһәрдә яшәүче 1200 кешегә кагылачак. Аларның 90ы – офицерлар. «Безнең Чаллыда үзгә характер. Ул эштә генә түгел, яу кырында да күренә. Барыбыз да хәрби ант бирдек. Безнең икенче Ватаныбыз да, икенче әниебез дә, запас аэропортыбыз да юк. Ватаныбыз биредә: яшәгән урыныбыз да, яшәгән җиребез дә шунда», – диде ул егетләрне озатканда.

Наил Мәһдиев әйтүенчә, киткән егетләрнең гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтеләчәк. Аларның мәктәптә укучы балаларын бушлай ашатачаклар, бакчага йөргән сабыйлар өчен дә түлисе булмаячак. Мондый ярдәм 1 октябрьдән күрсәтелә башлый. Автокаланың мәгълүмат сәясәте һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр идарәсе хәбәр итүенчә, мобилизациягә эләккән һәр кешегә шәһәр бюджетыннан 20шәр мең сум акча бүлеп биргәннәр. «Армиягә ярдәм күрсәтүне дә дәвам итәчәкбез. Ходайга өметләнәбез, барысы да яхшы булыр дип ышанабыз», – диде Наил Мәһдиев.

Түбән Камадан хәрби җыенга 38 кешене озаттылар. «Алар – бүгенге заман геройлары. Бабаларыбыз кебек батырлык һәм кыюлык күрсәтәләр», – диде якташлары турында район башлыгы Рамил Муллин. Бу атнада Түбән Камадан тагын бер төркем егет юлга чыгачак.

Татарстанның Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы өлешчә мобилизация кысасында районнардан 25 йөк машинасы бүлеп биргән.

Дөрес, мәшәкатьләр җитәрлек. Хәрби хезмәткә теләсә кемне алалар, яшенә дә, тәҗрибәсенә дә карап тормыйлар. Халык арасында да, социаль челтәрләрдә дә мондый хәбәрләр аз түгел. Моңа Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко да игътибар иткән. Ул төбәк җитәкчеләренә мөрәҗәгать итте һәм аларны өлешчә мобилизация эшендә җаваплы кешеләр дип атады. Аның сүзләренә караганда, кайчак дәүләтнең мөһим карарын сыйфатлы итеп үтәү түгел, тизрәк хисап тотарга тырышалар кебек тәэсир кала. «Илдә ватанпәрвәрлек, берләшү, безнең махсус хәрби операция максатларын хуплау дәрәҗәсе гаять югары булганда, мондый очраклар булырга тиеш түгел. Өлешчә мобилизация тиешле шартларга туры китереп, бер хатасыз алып барылсын», – диде ул.

Охшаш мөрәҗәгать белән Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин да чыкты. Хокук бозу очраклары булса, ул Дәүләт Думасына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирде. «Беркемне дә мәшәкатьләре белән үзен генә калдырмабыз. Һәр очракны аерым тикшерергә кирәк. Хата киткән икән, төзәтергә кирәк», – диде ул.

Төбәкләрдә өлешчә мобилизация турындагы указны бозып эшләүчеләр барлыгын Мәскәү Кремлендә дә таныдылар. Россия Президентының матбугат сәркатибе Дмитрий Песков әйтүенчә, барлык мәгълүматны төбәкләргә һәм Оборона министрлыгына җибәреп торалар. «Җитешсезлекләрне тиз арада бетерерләр һәм барлык хаталар төзәтелер дип өметләнәбез», – диде ул.

Моннан тыш, Дмитрий Песков хәбәрләр укыганда да игътибарлы булырга киңәш итте. «Сак булырга кирәк. Дөреслеккә караганда, ялган мәгълүмат күбрәк», – диде ул.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

МОБИЛИЗАЦИЯГӘ ЭЛӘККӘН КЕШЕГӘ ҮЗЕ БЕЛӘН НӘРСӘ АЛЫРГА ЯРЫЙ?

Бу сорауга җавапны «Объясняем.РФ» сайтында бирделәр. Анда әйтелгәнчә, мобилизациягә эләккән кешене хезмәт узу өчен тиешле барлык кирәк-ярак белән тәэмин итәләр. Шул ук вакытта үзең белән шәхси гигиена әйберләре, термокием, батарейкалар, яктырткыч, поход утыргычы, шлем эченнән кию өчен спорт баш киеме, тактик бияләйләр, теплоид (химик җылыткыч), мультититул (күпфункцияле җыйнак инструмент) алырга ярый.

Кием белән Оборона министрлыгы тәэмин итә. Шуңа күрә аның иң кирәклесен генә алырга киңәш бирәләр. Заманча телефон, ягъни смартфонны өйдә калдырырга туры киләчәк. Телефонның төймәлесен генә рөхсәт итәләр.

Канлы дүшәмбе

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Казан мэриясе дә кайгы уртаклашты: «Без Ижаудагы мәктәптә булган фаҗигадән тетрәндек. Удмуртия халкы белән бергә кайгырабыз. Без сезнең ни кичергәнне яхшы аңлыйбыз. Йөрәгебез һәм уйларыбыз белән».

Шаһитлар ни ди?

«Күпләрдә паника иде». Мәктәпнең технология укытучысы Дмитрий Викторович балаларның «канлы дүшәмбе»сен әнә шулай тасвирлый. Ничек итеп укучылар белән мәктәп бинасыннан чыгулары турында ул вакыйга урынында эшләгән матбугат чаралары вәкилләренә сөйләгән: «Башта бассейн артына качтык, аннан койма аша йөгердек. Күршедәге балалар бакчасына качмакчы идек, әмма тәрәзәдән күренербез, куркыныч туар дип, «Сбербанк» бүлекчәсенә киттек. Балаларның күбесендә паника башланды. Банк хезмәткәрләренә рәхмәт, су да бирделәр, урын да. Аннары инде балаларны ата-аналары килеп алды. Башкалар ничек качкандыр, безнең кабинетның аерым ишеге бар. Шуның аркасында гына кеше күзенә күренми кача алдык».

Ижевскида яшәүче милләттәшебез – өч бала анасы. Газизләре 84 нче номерлы мәктәптә белем ала. Фаҗига булган мәктәп алардан ерак түгел. «88 нче мәктәптә атыш булганнан соң, бик күп туганнар, танышлар: «Синең балаларың кайсы мәктәптә?» – дип хәл-әхвәл белеште. Әлеге мәктәп шәһәр администрациясеннән ерак түгел. 1200 бала укый анда. Бүген барлык мәктәпләрдә икенче смена дистанцион укытуга күчте. Бернинди түгәрәкләр дә булмаячак. Балаларны укудан дәресләр беткәнче килеп алдылар. Минем балалар үзләре кайтты. Өйгә кайтуга, укытучыга хәбәр җибәрдек. Бу җинаятьне кылган кешегә кеше дип әйтергә дә тел әйләнми. Нинди дөньядыр бу, әйеме?» – дип сөйләде ул.

Без дә әлеге вакыйгада зыян күрүчеләрнең, вафат булганнарның якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз! Чиксез сабырлык һәм кайгыны җиңәрлек көч телибез!

Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы зыян күргәннәргә тиешле ярдәм күрсәтү өчен Ижау шәһәренә белгечләр җибәрде. Казан һәм Чаллыдан күрше республикага 18 кешелек төркем Ми-8 вертолетында очкан. Белгечләрнең 10ы – Казаннан, калганнары – Чаллыдан. Фаҗига урынында республиканың нейрохирург, анестезиолог-реаниматолог, травматолог, психиатр һәм психологлары эшли.

Бер түләүдә

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Киләсе ел башыннан социаль түләү һәм субсидияләр дә артачак дип ышандыралар. Саннар теленә күчерсәк, хезмәт ветераннарына, дәүләт бүләкләре алган затларга бирелә торган айлык түләү 581 сум (әлегә 547 сум); 1941–1945 елда ким дигәндә ярты ел тылда булган затларга түләү – 867 сум (817 сум), мәктәпкәчә яшьтәге ятимнәргә бирелә торган түләү – 10326 сумга (бүген 9732 сум), мәктәп яшендәге ятимнәргә исәпләнгәне 11907 сумга (бүген 11222 сум) җитәчәк.

КАЙСЫ ТӨР ПОСОБИЕНЕ НИЧЕК АЛЫРГА?

	Иртә срокта исәпкә баскан йөкле хатын-кызларга айлык пособие	Бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие	1,5 яшькә кадәр түләнә торган айлык пособие	3 яшькә кадәрге айлык пособие	3–7 яшьлек балага айлык пособие	8–17 яшьлек балага айлык пособие
Кайчан тапшырырга	Йөклелекнең 12 нче атнасына кадәр исәпкә баскан очракта, бу пособиегә гаризаны бала тапканчы теләсә кайсы вакытта тапшырырга мөмкин.	Гаризаны бала тапканнан соң ярты ел эчендә тапшырырга кирәк.	Гаризаны балага 1,5 яшь тулганчы тапшырасы.	Гаризаны балага 3 яшь тулганчы тапшырасы.	Гаризаны балага 3 яшь тулгач, 7 яшь тулганчы тапшырырга кирәк.	Гаризаны балага 8 яшь тулгач, 17 яшь тулганчы тапшырырга кирәк.
Кайда тапшырырга	Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы яки Пенсия фонды аша тапшырырга була.	Рәсми рәвештә эшләүче ата-аналарга пособие автомат рәвештә билгеләнә. Эшләмәүче ата-ана исә күпфункцияле үзәк яки Пенсия фонды аша гариза тапшырырга тиеш.	Рәсми рәвештә эшләүче ата-ана гаризаны эш бирүчегә, эшсезләр Пенсия фонды яки күпфункцияле үзәк, шәхси эшмәкәрләр социаль иминиятләштерү фонды аша тапшыра ала.	Беренче балага пособие алу өчен гаризаны – Пенсия фондына, икенче бала өчен Пенсия фондына яки күпфункцияле үзәккә, өченче һәм аннан соңгы бала өчен социаль яклау идарәсенә тапшырырга кирәк.	Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы, күпфункцияле үзәк яки социаль яклау идарәсенә тапшырырга кирәк.	Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы, күпфункцияле үзәк яки Пенсия фонды аша тапшырырга кирәк.
Гаризаны озайтырга кирәкме?	Гаризаны озайтасы юк.	Гаризаны озайтасы юк.	Гаризаны озайтасы юк.	Гаризаны ел саен тапшырып, яңартып торырга кирәк.	Гаризаны ел саен озайтасы.	Гаризаны ел саен озайтырга кирәк булачак.

Авыл хуҗалыгы

Татарстанда бөртеклеләрне җыю ахырына якынлаша, төп эшләр инде тәмамланды дип әйтергә мөмкин. Татарстанның Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров Татарстан Министрлар Кабинетында узган киңәшмәдә әнә шулай дип белдерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТАТЛЫ АЗЫК

ШИКӘР ЧӨГЕНДЕРЕН ҖЫЮ ДӘВАМ ИТӘ

Соңгы мәгълүматлар буенча, бүгенгә 5 млн 345 мең тонна ашлык җыеп алынган. Бөртекле культураларның иң зур мәйданнары Әлки, Чистай һәм Яңа Чишмә районнарында. Шул ук вакытта 11 район суктыру эшләрен башлаган, 9,2 мең тонна суктырылган.

Хәзер игенчеләр кырларда кукуруз, рапс җыю белән мәшгуль. Министр әйтүенчә, республикада кукуруз мәйданы 46,4 мең гектарны тәшкил итә. Барысы бергә 100 мең тонна кукуруз җыеп алырга уйлыйлар. Шулай ук авыл хуҗалыгы оешмалары яшелчәләрне дә җыеп урнаштыра. Яшелчәчелек белән шөгыльләнүчеләр бәрәңге ала. Әлеге вакытта икенче икмәкнең уртача уңдырышлылыгы гектарыннан 310 центнерны тәшкил итә.

Моннан тыш, республика кырларында татлы азык – шикәр чөгендерен җыю дәвам итә. 50 мең гектарның 18 мең гектарга якыны казылган. Уңдырышлылыгы гектарыннан 339,9 центнер чыга. Әлегә 671,1 мең тонна шикәр чөгендере казылган.

– Шикәр чөгендере утыртылган кырларда 76 махсус комбайн эшли. Яхшы һава шартлары булып, эш планлаштырылганча барса, 1,7 мең гектарга кадәр тамыразык казып, шикәр чөгендерен 20–25 көн эчендә җыеп алу мөмкинлеге бар, – ди Марат Җәббаров. – Көненә уртача 1 мең гектарда эшләр башкарыла. Ике шикәр заводы да эшкәртә. Яңа уңыштан 28,1 мең тонна шикәр җитештерелгән. Шикәр күләме 14,8 процентны тәшкил итә.

Министр хәбәр итүенчә, агымдагы ел ахырына кадәр федераль һәм республика программалары хисабына өстәмә 3,4 мең гектар сугарулы җирләр сафка кертеләчәк.

Билгеле булганча, Татарстанда шикәр чөгендерен ике районда эшкәртәләр. Аның берсе беренчеләрдән булып урып-җыюга керешеп, аны лидерлар сафында тәмамлаган Зәй районында урнашкан. Икенчесе – Буада. Зәй районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Фәргать Камалиев «ВТ»га сөйләвенчә, хуҗалыклар рапс, гәрчич һәм шикәр чөгендере алу белән мәшгуль.

Соңгысы районда 8905 гектарда чәчелгән. Бүгенгә шуның 60 процентында эшләр тәмамланган. Уртача уңдырышлылык гектардан 358 центнер чыга.

– Шикәр чөгендеренең иң нык үсә торган вакыты август – сентябрьгә туры килә. Ә бездә июль уртасыннан башлап сентябрь башына кадәр яңгырлар яумады. Шул сәбәпле көтелгән рекордлы уңыш алып булмады. Югыйсә тагын да мул уңышка өметләнгән идек. Менә бу яңгырлар аны тагын үстерер әле дип уйлыйм. Шулай да, елына караганда уңышны начар дип әйтеп булмый, – диде Фәргать Камалиев.

Ул Зәй шикәр заводының көненә 7–7,5 мең тонна шикәр эшкәртүен әйтте. Бу – көн саен 1200 тонна шикәр комы чыга дигән сүз. Сарман, Тукай, Зәй районнарыннан 8–9 мең тонна шикәр чөгендере кабул ителә икән бирегә.

– Башка еллар белән караганда, быел шикәр татлырак, баллырак. Бу беренче чиратта чөгендернең сортына бәйле. Баштагы вакытларда 19–20 процент шикәрлелек белән тапшырган идек, бүген 15 процент белән чыгаралар. Завод тулы куәтенә эшли, тик авырлыклар да бар бераз. Безнең техникаларның барысы да – Германиянеке. Ватылып киткән очракта, запас частьлар табу авырлашты быел. Аңа карамастан, график буенча барабыз. Эшләр шулай яхшы гына дәвам иткән очракта, октябрьнең 15еннән дә калмыйча төгәлләрбез дип уйлыйм, – диде ул.

Соңгы бер-ике көндә авыл хезмәтчәннәрен яңгырлар да явып сөендерде. Күптән көтелгән, шифалы явым-төшем бу, дип шатлана ала.

– Район буенча уртача алганда 20 мм булды. Бик әйбәт бу, – диде Фәргать Камалиев та. – Тишелеп бетмәгән уҗымнар өчен файдасы әйтеп бетерерлек түгел. Дымлылык җитмәгәнлектән, көзге культуралар авырлык белән үсә иде. Туфрак та каты, кәсле булды. Бу яңгырлар комбайннарның да эшен җиңеләйтер дип өметләнәбез. Чөгендергә дә файдасы булыр дип уйлыйм.

Җитәкчедән шикәргә бәя буенча да кызыксындык. Аның фикеренчә, уңышка караганда, татлы ризыкның бәясе артырга тиеш түгел. Тик шулай да ул алдан фаразларга тәвәккәллек итмәде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КИМ ТҮГЕЛЛӘР!

Авыру балаларның күбесе өйдә түгел, мәктәптә укый хәзер. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, узган уку елында аларның 12 меңнән артыгы укырга йөргән. Бу сан елдан-ел арта бара. Мондый балаларга карата җәмгыятьнең фикере үзгәрдеме? «ВТ» хәбәрчесе инклюзив белем бирүнең тискәре һәм уңай яклары турында белеште.

Бу теманы язганда, инклюзив белем бирү өлкәсе белгечләре гадәттә авыру түгел, үсешендә үзенчәлекләр булган, сәламәтлекләре чикләнгән, дип төзәтә. Мөмкинлекләре чикле дигән сүзне дә хупламыйлар. Ни өчен дигәндә, сәламәт балаларга караганда, алар күпкә тырышрак, үҗәтрәк тә әле. Белгечләр безне сак булырга чакыра. Тәҗрибәмдә шундый хәл дә булды. Бер әни коррекцион сыйныфтагы балаларны авыру дип язган өчен бик каты итеп сүккән иде. Менә шундый бик четерекле тема бу.

– Бүген әти-әниләр үсешендә үзенчәлекләр булган балаларны махсус учреждениеләрдә һәм гади мәктәпләрдә укыта ала. Бүген аларга карата укучыларның мөнәсәбәте уңай. Сыйныф сәгатьләрендә, шулай ук аерым укучылар белән толерантлык турында сөйләшүләр уздырыла. Белгечләр җитә. Мәктәпләрдә уңайлыклар тудырылган, укыту өчен кирәк-яраклар сатып алына. Кул хезмәте белән шөгыльләнү өчен остаханәләрне, психолог, логопед кабинетларын җиһазландыруга зур игътибар бирелә. Шулай ук укыту программалары да стандартларга туры китереп яңартыла, – диделәр безгә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгында.

Казан инновацион университеты ректоры урынбасары, инновацион педагогика һәм инклюзив белем бирү фәнни тикшеренүләр институты директоры Дания Әхмәтова белән бу төр белем бирү турында сораштык.

– «Мәгариф турында»гы Законда, мәктәптә укый алмый торган бер генә бала да юк, диелгән. Авырулары бик күп булганда гына гади мәктәптә укый алмыйлар. Мин Германия мәктәпләрендә андый балалар белән эшләү тәҗрибәсен күрдем. Бер балага 4–5 инструктор ярдәм итә. Бездә андый мөмкинлек юк. Шулай да тьюторлар бирәләр. Хәзерге белем бирү процессын бары инклюзия юлыннан гына дөрес итеп алып барырга мөмкин. Бу – хәзерге заманда иң кирәкле әйбер. Мәктәптә һәр балага белем алуда тигез мөмкинлек бирергә кирәк. Европада инклюзив белем бирү 50 ел элек тормышка ашырылса, бездә ун ел эчендә дә күп эшләр башкарылды. Хәзерге вакытта мәктәпләрнең яртысы диярлек инклюзия тибына керде, – ди Дания Әхмәтова.

Белгеч белдергәнчә, бу темага сораштыру уздырган булганнар. Анда республикадагы 600ләп бакча, мәктәп, һөнәри уку йорты катнашкан. Нәтиҗәдән күренгәнчә, укытучыларның 65 проценты мондый балалар белән үзләрен тыныч тота белми, чөнки алар белән эшләү җиңел түгел.

– Мин элек мәктәп директоры булып эшләдем. Ул вакытта инклюзия сүзен дә белмәгәнбез. Авыру балалар күп иде, барысын да укытып чыгардык. Арада бик начар күргәне, ишеткәне дә, аксап йөргәннәре дә, дауннар да булды. Директор, бакча мөдире, ректорлардан да күп нәрсә тора. Тик алар авыру балаларны алырга бик атлыгып тормый. Авыру балаларны сәламәт укучылар төрлечә кабул итә. Дөрес итеп аңлатсалар, бернинди кыенлык та юк. Балалар бакчасы, башлангыч мәктәптән үк инклюзив белем бирүне керткәндә, эш җиңел барачак. Педагогик һәм психологик ярдәм дә кирәк. Без фәнни-методик үзәк булып торабыз, укытучыларны укытабыз, семинарлар үткәрәбез.

Илүсә Назарова Казан мәктәпләренең берсендә укыта. Аның әйтүенчә, авыру балалар белән эшләү тәҗрибәсе бөтенләй юк.

– Минем фикерем бер төрле генә түгел. Бер караганда, авыру балаларның әниләрен дә аңлыйм. Аларның ул-кызларын тормышка яраклаштырасы, мәктәптә укытасы килә. Тик шул ук вакытта укытучыга авыру балалар белән эшләү бик авыр. Алар бит аеруча игътибар сорый. Шул ук вакытта алдынгы укучылар, башкалар белән дә эшләргә кирәк. Укытучы бит берьюлы берничәгә бүленә алмый. Монда бик зур сабырлык кирәк, мин болай эшли алмас идем. Шуңа күрә инвалид балаларны аерым сыйныфларда, махсус укытучылар укытырга тиеш дип саныйм, – ди Илүсә Назарова.

Балтач районының Карадуган мәктәбенең инклюзив белем бирү эшләре буенча директор урынбасары Гүзәл Закирова белән үзенчәлекле балаларны укыту турында сөйләштек.

– 2018 елда аерым сыйныфлар булдырдык. Эшне 18 бала белән башлап җибәргән идек, хәзер бу сан 26га җитте. Алар районның 12 авылыннан килеп укый. Көн саен өйләренә кайтып йөриләр. Моңа кадәр өйдә укучылар да бар иде. Безгә килгәч, үз эченә бикләнгән балалар ачылып китә. Аларга берәү дә бармак төртеп күрсәтми. Балалар булышып тора. «2ле»ләр куймыйбыз, ә яхшы билге алсалар, кош тоткандай сөенәләр, өй эшләрен дә тырышып эшләп киләләр, – ди Гүзәл Закирова.

Аның әйтүенчә, төп бурыч – сәламәтлеге чикләнгән балаларны тормышка әзерләү. Кызлар – тегү, малайларны агач эшенә өйрәтәләр икән. Хезмәт дәресләре атнага 6–14 сәгать керә. 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, техникумнарга укырга урнаштыралар. Алар арасында пешекче, төзүчеләр бар.

– Бер теләгем бар иде. Балаларга дидактик материаллар, уенчыклар җитми. Шулар белән ярдәм итсәләр иде, – ди Гүзәл Закирова.

Казанның Дәрвишләр бистәсендә яшәүче Камил Мифтахетдиновның аяклары авырта. Бу мәктәпкә бармаска сәбәп түгел. Менә тугыз ел инде ул яшьтәшләре белән мәктәптә укый. Укуын тәмамлагач, йә журналист, йә программист белгечлеген сайларга җыена.

– Укытучыларның да, балаларның да мөнәсәбәте яхшы. Гарип бала дип карамыйлар. Кечкенә чакта читенсенгән чаклары бар иде. 5 нче сыйныфтан соң үзгәрде. Кимсенү, төшенкелек булмады, Аллага шөкер. Мәктәпкә килми торса, иптәшләре юксына башлый. Баскычтан төшкәнен күрсәләр, юл бирәләр, этеп җибәрү, тупаслык юк, – ди әнисе Алсу. – Бик теләп йөри мәктәпкә. Тормыш авырлыкларына яраклаша белүе куандыра. Авыру балаларны өйдә утыртырга кирәкми, алар үз эченә бикләнәчәк. Әти-әни гомер буе янында терәк булып тора алмый бит. Без утын кискәндә дә улыбызны ярдәмгә алып чыктык. Яратырга да, иркәләргә дә кирәк, артык кызганырга ярамый.

Сәрия МИФТАХОВА

КАПКАЛАР

Әллә нишләдек без соңгы арада. Аралашмый башладык, үзебезгә бикләндек. Хәтта күршеләрнең үлемен дә «Ватсап» аша гына беләбез. Элегрәк болай түгел идек…

И, күңелле булган икән элек. Кешеләрнең күңеле ачык иде. Урам буйлап барасың, кемдер очрый, әллә каян кул болгап, я баш кагып сөрәнли: «Сәлам, туган! Хәлләрең ничек?» Вакыты бик тыгыз булмаса, килеп күрешә. Син дә сөрәнлисең, аңа каршы барып кул сузасың. Юк-бар нәрсәләр турында сөйләшеп аласың да ары китәсең. Моның ни дәрәҗәдә мөһим, җанга җылылык һәм яктылык өстәүче күренеш икәнен мин хәзер генә аңлыйм. Кешеләрнең барлыгын, бер-берсенә, шул исәптән сиңа да битараф түгеллеген тоеп яшәүнең бер чагылышы бит инде бу. Зур нәрсә. Ул чакларда, әлбәттә, болай тоелмый, нәкъ шулай булырга тиешле гадәти бер күренеш сыман күренә иде.

Эшнең кызу вакытларында, әйтик, печән өстендә бу аеруча нык сизелә иде. Машина-трактор табу авыррак иде ул чорларда. Колхоз эше дә күп, печән ташырга теләүчеләр чираты да зур. Күтәргә туры килә инде. Ләкин беркемнең дә чапкан печәне урманда калмый, барысына да җай табыла. Трактор булу белән төяшергә кеше эзләп күрше-күләнне урап чыгасың. Кайсы өйдә булмый, кайсының кичектергесез мәшәкате бар. Шулай да кеше табыла. Күпләре кадак кагарга дип күтәргән чүкечен ташлап сиңа иярә. Ашыгыч эш икәнен барысы да аңлап тора инде. Печән алып кайткач, төяшергә бара алмаган күрше-күлән сәнәкләрен күтәреп, аны бушатышырга килеп җитә. Сөенәсең. Эш бит ул кешенең күплеген ярата.

Бәрәңге утырткан-алган чорларда да шул чамарак була торган иде. Кулалмаш дип әйтеп булмый инде моны. Мин күп кешеле гаиләдә үсмәгәч, берсенә дә керә алмый, үзебездән артмый торган идем. Ә күп кешеле күршеләр үз бакчаларын тиз генә эш итеп бетерәләр дә, көрәк-чиләк тотып, ярдәмгә килеп җитәләр. И, ни генә кылсак та, күршеләр белән яши идек инде. Алар синнән берәр нәрсә сорап керә, син алардан нидер алып торасың. Күршеләр дип әйтү генә дөрес түгел бугай әле ул, бөтен авыл кешесе бик якын булып, үзара аралашып яши. Ярдәм дә итәләр, сорап та киләләр.

Эш вакытларында гына түгел, бәйрәмнәрдә дә бергә иде халык. Каз өмәләре, сугым чоры үзенә күрә бер Сабантуйга әйләнә торган иде. Хәтта күрше авыллардагы туган-тумача да ат чанасында толыпка төренеп килеп җитә. Бик исерүче дә, умырып ашаучы да булмый инде, аралашу өчен җыелалар. Туганнар, дус-ишләр белән табын янында утыру үзенә күрә зиннәтле бер бәйрәм кебек тоела.

Гадәти көннәрдә дә күрше күршегә кереп хәл белешеп чыга. Еррак яшәгәннәре дә килеп китәли. Чәйләп утыралар. Сыйлы чак булса, сыйга эләгә инде килгән кеше, андый вакыт туры килмәсә, коры чәй белән чикләнә. Бу мөһим дә түгел. Иң мөһиме – кереп хәл белешеп чыгу. Сөйләшеп утыру. Шулай гәпләшеп, эч серләрен бүлешеп, күңелен бушатып, җанына җылы алып яши иде кеше бер-берсеннән.

Җәйләрен капка төбенә чыгып гөрләшеп утыруны инде сөйлисе дә түгел. Капка дигәннән… Элек аны бикләп кую гадәте бөтенләй юк иде бугай. Ул чакта да бурлык бар иде инде ул. Балта-пычкыны да, көрәк-сәнәкне дә, башкасын да кыстырып чыгып китүчеләр булгалый иде. Абзарга кереп кош-корт урлап чыгучылар да табыла иде. Тик капкалар беркайчан да бикләнми торган иде. Капкалар да, ишекләр дә, күңелләр дә һәрвакыт ачык иде.

Үзгәрдек хәзер. Үзебезнең ничек үзгәргәнебезне үзебез дә сизми калдык бугай. Йомышыбыз гына төшмәсә, беркемгә дә барып утырмыйбыз, үзебезгә дә килмиләр. Көрәк-сәнәк сорап йөрү гадәте дә юкка чыкты. Күршеңә ниндидер эш коралы сорап керү бераз гаеп тә булып тоела бугай әле ул. Тормыш җитеш хәзер, һәркемнең үзенеке бар. Булырга тиеш. Чынлап та хәзер кешенең бөтен нәрсәсе дә бар, берәүгә дә мохтаҗлыгы юк. Ашы да, эше дә, эш коралы да үзендә. Хәзер кешегә шул эш кораллары ярдәм итә, күршеләре, дуслары, туганнары түгел. Каз өмәсе, сугым чоры дигән нәрсәләр дә юкка чыкты. Кемнең нәрсә чалганын белми дә каласың. Кешене эшкә чакыру мохтаҗлыгы булмагач, ашка чакыру теләге дә юк. Бергәләп эшләмәгәч, бергәләп бәйрәм итәсе дә килми. Белмим, яхшы микән инде бу, начар микән… Хәзер һәр йорт мөстәкыйль бер дәүләт булып яши. Шулай булгач, дәүләтнең мөстәкыйльлеге дә артык мөһим түгел.

Тик кайвакытларда мин элекке чорны сагынам. Кешеләр арасындагы җылылык юксындыра. Бу дөньяда кеше булу гына җитми, кешелекле дә булырга кирәктер сыман тоела. Эх… Әллә нишләдек без соңгы чорда…

Шундый моңсу уйларга бирелеп капканы бикләп кердем әле. «Чукынып йөрмәсеннәр».

Югыйсә шәрран ачып куйсаң да, эт тә килми инде анда…

Марат КӘБИРОВ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

21 сентябрь, 2022 ел Казан ш. № 181/1582

2022 елның августында төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның августында төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 15 сентябрь, 2022 ел, № 104 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елның августында төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 15 сентябрь, 2022 ел, № 104 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2022 елның августында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның августында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

4. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

5. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Сквордяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С.Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты администрациясе, «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыяте генераль директоры

САБИРОВ Ринат Касыйм улының

гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Ринат Сабировның арабыздан мәңгегә китүе республиканың бөтен җәмәгатьчелеге өчен көтелмәгән югалтуга әйләнде. Ул максатка омтылышлы, талантлы җитәкче, үз эшенең остасы иде. Коллегалары арасында тел-теш тидергесез абруй-хөрмәткә ия булды.

Хезмәт биографиясенең 20 елдан артыграк дәвере дәүләт хезмәтенә бәйле. Ул озак еллар буе Татарстан Республикасы Президентының нефть-газ-химия комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе вазыйфасында хезмәт куйды. Аның катнашында бу тармакта югары технологияле яңа производстволар булдырылып гамәлгә кертелде.

Ринат Касыйм улы Сабировның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыяте генераль директоры

САБИРОВ Ринат Касыйм улы

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе **Кашапова** Эльмира Вафа кызына, рәссам, «Чаллы шәһәре картиналар галереясы» муниципаль бюджет учреждениесе музее бүлеге (секторы) мөдире, «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Мингалиев** Марат Искәндәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артистлары: **Галимуллина** Гөлназ Марсель кызына, **Фәйзуллина** Алсу Фәнис кызына, **Шакирова** Алсу Ринат кызына, «Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе вокалчы артисты (солисты) **Церерина** Зоя Андреевнага **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Я. Купала музее мөдире **Абызова** Римма Юрьевнага, Казан шәһәренең «Рөстәм Яхин исемендәге 3 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы **Вәлиева** Гүзәлия Мөхәммәтзәки кызына, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең кадрлар бүлеге башлыгы **Гайнатуллина** Миләүшә Рәүф кызына, Казан шәһәренең «П.И. Чайковский исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано укытучысы **Ганиева** Резеда Җәүдәт кызына, «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе өлкән администраторы **Гарипов** Рамил Равил улына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе контроль, аналитика һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы **Камалова** Рузилә Рафикъ кызына, «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының административ-хуҗалык часте буенча урынбасары **Мифтахов** Илмир Нух улына, Татарстан Республикасының «Республика яшүсмерләр китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең хезмәт күрсәтү бүлеге баш китапханәчесе **Мифтиева** Фәридә Илдус кызына, «Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең вокал укытучысы **Сёмина** Елена Ниловнага, «Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры ярдәмчесе **Феоктистова** Наталья Вениаминовнага, Казан шәһәренең «4 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Яхина** Альбина Әхәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет оешмасы тренеры **Ахметов** Фәрит Ислямутдин улына, «Барс» спортның кышкы төрләре буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе тренеры **Лобашов** Василий Алексеевичка, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Нәбиуллин** Илфат Нәҗип улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе җитәкчесе **Әхмәтханов** Җәүдәт Йосыф улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

Белдерү

Кадастровым инженером Хабибуллиным Ильдаром Ибрагимовичем (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера 16-14-724, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11, 420107, ildarkhabib@mail.ru, тел.: +79272414666, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 31944) проводятся кадастровые работы в отношении земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, п. ИЖС «Алтан», ул. Заветная, д. 18 с кадастровым номером 16:50:160714:1.

Заказчиком кадастровых работ является Булнина Анастасия Сергеевна, контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, п. ИЖС «Алтан», ул. Заветная, д. 18. Тел.: +79272414666.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11 4 ноября 2022 г. в 10.00 ч.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 3 октября 2022 г. по 3 ноября 2022 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 3 октября 2022 г. по 3 ноября 2022 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:160714:11 (Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, п. «Алтан», ул. Серле, д. 17).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. №221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Спорт

Күп булуның артыгы юк

Ниһаять! «Ак барс» хоккейчылары бер кешегә күбрәк уйнауның бәрәкәтен күрә башлады. Көндәшнең кагыйдә бозуыннан ике мәртәбә уңышлы файдаланып, Казан командасы үз бозында «Трактор»дан өстен чыкты. Бу җиңүдә Зиннәтулла Билалетдиновның да өлеше бар.

«Трактор»га 1:2 исәбе белән оттырып барган «Ак барс» өченче периодта 5 минут эчендә ике алка кертеп, уенның язмышын хәл итте. Иң мөһиме – Казан командасы ике алканы да күплектә уйнаганда, ягъни көндәш кагыйдә бозгач кертте. Олег Знарок уенчылары мондый мөмкинлекне 33 мәртәбә кулдан ычкындырган һәм бу күрсәткеч буенча КХЛда иң соңгы урында бара иде. Хәлиткеч алкаларны башта Вячеслав Войнов, аннары Станислав Галиев кертте. Сүз уңаеннан, икесенең дә яңа сезондагы беренче голлары. «Җилкәдән йөк төшкәндәй булды», – диде очрашуның иң яхшы уенчысы булып табылган һәм шуның хөрмәтенә башына түбәтәй кигән Галиев.

«Спартак»ка оттыру белән тәмамланган алдагы матчтан соң «Ак барс»ның баш тренеры Олег Знарок журналистлар белән әйткәләшеп алды. Каләм әһелләре әллә ни җайсыз сораулар да бирмәде үзе. Әмма командасының җиңелүен авыр кичергән остазның кәефе юк иде. Уеннан соң алар төнгә кадәр тренерлар белән авыр хәлдән чыгу юлларын эзләгән. Җыелышта Казан клубының башкарма директоры киңәшчесе Зиннәтулла Билалетдинов та катнашкан. Танылган ике тренер Казанга килгәч, аларның бер командага сыеша алмаячагын фаразлаучылар да булды. Әмма Знарок белән Билалетдиновның бозда да, аннан читтә дә тормыш тәҗрибәсе җитәрлек. Знарок үзе дә Билалетдиновны ишетергә әзер булуын яшерми. Бу юлы бер-берсенә колак салуларының нәтиҗәсе булды. «Егетләр күплектә алка кертә алмаганнарына бик борчылды. Әлбәттә, бу мәсьәләдә сораулар күп иде. Уенчылар яхшы, ник кертә алмыйлар? Әмма үз дигәннәренә ирешә аласыларына шикләнмәдек. Бүген, ниһаять, килеп чыкты. Алга таба да шулай булыр дип уйлыйм», – дигән Зиннәтулла Билалетдинов ТАСС хәбәрчесенә.

Дөрес, бу әле «Ак барс»та барысы да тәртиптә дигән сүз түгел. «Трактор»га каршы уенда, мәсәлән, Дмитрий Кагарлицкий бозга чыкмады. Узган ел команданың иң нәтиҗәле уенчысы булып танылган һөҗүмченең быел нибары 2 очкосы бар. Бер алка да кертә алмады. «Юк, без аны запаска утыртмадык. Ул – безнең команда уенчысы. Уенчыларны алмаштырып торабыз. Безгә ял иткән һәм сәламәт уенчылар кирәк», – диде Олег Знарок. Аның сүзләренә караганда, теләсә кайсы уенчыны ялга җибәрергә мөмкиннәр. Әлегә исә команданың алыштыргысыз бердәнбер хоккейчысы дип Александр Радуловны телгә алырга мөмкин. НХЛдан кайткан һөҗүмче барысына да өлгерә. Һөҗүмгә дә бара, көндәшне дә кызганмый, иптәшләрен дә тик утыртмый. «Трактор»га каршы узган очрашуда Станислав Галиевка нәтиҗәле пас биреп, ул КХЛ тарихында иң нәтиҗәле ассистентлар исемлегендә өченче урынга чыкты. Аның исәбендә 392 пас бар. Данис Зарипов 391 пас белән дүртенче урында калды. Ә беренчелек Вадим Шипачевта (556). Дөрес, Казанга килгәч, Вадим нәтиҗәле уены белән мактана алмый. Соңгы елларның иң уңышлы һөҗүмчесе «Ак барс»та нибары 1 алка кертте һәм 2 пас бирде.

Казан командасы турнир таблицасында өченче урынга күтәрелсә, «Нефтехимик» иң аста баруын дәвам итә. Түбән Кама хоккейчылары быелгы сезонда әле бер мәртәбә җиңү тәмен татый алмаган бердәнбер команда булып кала бирә. Якташларыбызның 10 матчта нибары 1 очкосы бар. Атна ахырында «Нефтехимик» капкачы Эмиль Гарипов белән килешү төзеде. Бу гына ярдәм итәрме?

КӨНЧЫГЫШ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

	команда	уен	очко
1	Металлург	10	16
2	Автомобилист	10	15
3	**Ак барс**	**9**	**13**
4	Сибирь	11	13
5	С. Юлаев	10	12
6	Авангард	11	9
7	Барыс	10	9
8	Адмирал	10	9
9	Амур	10	9
10	Трактор	11	8
11	Нефтехимик	10	1

ak-bars.ru

Икенче җиңелү

«Рубин» беренче лигада икенче мәртәбә җиңелүгә дучар булды. Казан командасы 0:1 исәбе белән Ярославльдә җирле «Шинник»ка оттырды.

	команда	очко
1	Алания	22
2	Балтика	22
3	Арсенал	19
4	**Рубин**	**19**
5	КАМАЗ	19
6	Динамо	18
7	Енисей	17
8	СКА-Хабаровск	16
9	Волгарь	16
10	Нефтехимик	15
11	Шинник	15
12	Уфа	13
13	Кубань	11
14	Краснодар-2	11
15	Велес	10
16	Родина	8
17	Акрон	8
18	Волга	5

rubin-kazan.ru

БАЛА ТЕЛЕНДӘ

ТАТАРЧА ЭНЦИКЛОПЕДИЯЛӘР КЫЗЫКСЫНУ УЯТТЫ

Әйләнә-тирә турында туган телләрендә өйрәнсеннәр. Әнә шундый максат белән быел Татарстан китап нәшрияты мәктәпяшендәге балалар өчен «Балалар энциклопедиясе» сериясендә китаплар чыгарды. Аларга ихтыяҗ бармы? Китапларны тәрҗемә итүдә нинди кыенлыклар булган?

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә Мәскәүнең «РОСМЭН» нәшрияты белән берлектә ун китап тәрҗемә ителеп бастырылган. Китапларның гомуми тиражы – 5 мең.

Нәшриятның балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты, махсус проектлар редакциясе мөдире Айсылу Галиева әйтүенчә, һәр бала китаплардан әйләнә-тирә турындагы кызыксынган сорауларына җавап таба ала. Китапларны дәресләрдә өстәмә материал буларак та кулланырга була. «РОСМЭН» нәшрияты кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен чыгарган китаплар арасыннан «Илләр һәм континентлар», «Авиация», «Бөҗәкләр», «Бизнес», «Этләр», «Гаҗәеп хайваннар», «Диңгезләр һәм океаннар», «Астрономия һәм космос», «Футбол», «Терек табигать» китаплары тәрҗемә ителгән.

– Тәрҗемәчеләрне Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тәкъдиме буенча сайлап алдык. Балалар әдәбиятына якын булган, үзенең тәрҗемә иткән өлкәсен биш бармагы кебек белгән кешеләргә йөкләнде бу эш, – диде Айсылу Галиева. – Энциклопедияләрнең 3000е мәктәпләргә таратылды. Теләгән кеше сатып та алсын дип, 2000е сатуга чыкты. Кибетләрдә бар, әйбәт сатыла. Редакцияләү җиңел эш түгел, бик күп сүзлекләр белән эшләргә туры килде. Кайбер сүзләрнең тәрҗемәләре юк, кайсылары төрлесендә төрлечә тәрҗемә ителгән. Катлаулы, әмма файдалы эш булгандыр дип ышанам. «Нәрсәгә кирәк инде болар» дигән сүзне ишеткәнебез юк, киресенчә, «Нигә моның турында юк, ә бусы турында кайда?» – дип сорыйлар.

«Сөембикә» журналының әдәби бүлек мөхәррире Эльмира Закирова «Бизнес» сериясендәге энциклопедияне тәрҗемә иткән.

– «Ялкын» журналында эшләгәндә мин балаларга бизнес турында дәресләр алып бардым. 1995–1997 еллар, «бизнес» төшенчәсенең килеп кенә кергән чагы иде ул. Шуңа күрә ул вакытта балалар аеруча кызыксына иде. Мин Мәскәүдән кызыклы китаплар алып кайттым, журналистлар тәрҗемә итте. Тема сезгә якын, дип миңа тәкъдим иткәч, бу эшкә бик теләп алындым, – ди Эльмира Закирова. – Рус, чит телләрдән кергән терминнар бераз кыенлыклар тудырды. Аларны татар телендә табарга кирәк иде. Әле шул ягы да бар: балалар бит озын җөмлә белән язганны кабул итмиләр. Күз алдына китерер өчен аларга барысы да кыска һәм аңлаешлы булырга тиеш. Төрле китаплардан карап җәмгыять, илләр тарихы, сәүдә мөнәсәбәтләре, акча бирәмлекләре, бизнес юлындагы аерым бер сәясәтчеләр турында мәгълүматны өстәдек. Интернеттан да, башка чыганаклардан да карап, тулырак булсын дип тырыштык. Татар телендә бизнес, аның нечкәлекләре турында аңлата торган китап булырга тиеш иде. Килеп чыкты дип уйлыйм.

Энциклопедияләр арасында «Футбол» сериясендәгесенә ихтыяҗ зур икән. Аны «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире Атлас Гафиятов тәрҗемә иткән.

– Эшнең әллә ни кыенлыгы булмады. Берникадәр вакыт алды инде: энциклопедияләр актарырга кирәк булды. Спортның бит үзенең махсус терминнары бар. Әйтик, «трибуна»ны – тамашачылар утыра торган урын, «гол»ны капкага туп керү дип тәрҗемә иттек. Татар телендә балалар өчен мондый энциклопедия юк иде әле, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Атлас Гафиятов спортның башка төрләре турында да энциклопедияләр булдырырга кирәк дигән фикердә:

– Балалар өчен спорт буенча методик ярдәмлекләр әз. Көрәш турында эшләргә була. Малайларга кызык бит. Көрәш буенча тренер Вакыйф Дәүләтшинның китабы бар. Заманында миңа аны редакцияләргә туры килде. Без укыганда мондый китаплар бөтенләй юк иде. Балалар русчаны, инглиз телен белә, андыйларны болай да укыйлар. Татарча энциклопедияләр кирәк иде. Үземнең оныкларга да бирдем, авылга китапханәгә, үзем укыган мәктәпкә алып кайтырга исәп бар, – диде Атлас Гафиятов.

Энциклопедияләрне сатып алучы әти-әниләрнең дә фикерен белештек. Казанда яшәүче Гөлнур Фәрхуллина 3 яшьлек улы Шамилгә энциклопедиянең «Бөҗәкләр» дигән сериясен алган. Әле укый белмәсә дә, бөҗәкләрнең фотосурәтләрен бик кызыксынып карый, ди Гөлнур.

– Бу сериядәге китаплар бик ошый. Улым бөҗәкләрне бик ярата, шуңа күрә матур-матур рәсемнәре булу аеруча сөендерде. Шамил рәсемнәргә карап, һәрбер бөҗәкнең исемен сорый, мин аңлата барам. Мәктәпкә баргач, укырбыз да әле, Алла боерса. Миңа калса, бала кечкенәдән әйләнә-тирә дөньядагы хайваннар, кошлар, бөҗәкләрнең татарча атамасын белергә тиеш.

Ләйсән САФИНА

ХӘЕРЛЕ КӨН!

«Татар-информ»

Мәдәният дөньясында

Казанда Зөлфәт Хәкимнең шушы исемдәге икенче концерты шаулап узды. Беренчесе май аенда үткән иде. Ул чакта концертка ике атна кала билетлар сатылып бетте. Икенчесендә дә буш урыннар юк иде. Шулкадәр күңел кылларын тибрәтерлек, уйландырырлык, шөкер иттерерлек концерт булды ул. Тәнәфескә дә бүленмичә, Зөлфәт абыйны тыңладык. Тамашачының аның җырлавына сусаганын, һәр җырын алкышлар белән каршы алуын күрү дә рәхәт иде.

Зөлфәт Хәким – 6 роман, 8 повесть, 50 пьеса, 700ләп афоризм, бик күп хикәяләр авторы. Аның 30лап әсәре татар, башкорт, мари, Кырым сәхнәләрендә куелган. Ә җырлары инде ничә еллар үз популярлыгын югалтмый.

– Миндә өч ел элек яман чир таптылар. 4 атна гомерең калган, дигәч, бик курыктым. Үлемнән түгел, сезне – тамашачыларны күрә алмаудан курыктым. Әмма, шөкер, мин исән, алдыгызда басып торам, – диде Зөлфәт Хәким. – Германия белән Казан арасында йөри башлагач, уйланырга вакыт күп булды. Яңа җырлар язылды, китап әзерлим. Исән-имин чакта бер-береңнең кадерен бик белеп бетермисең инде ул. Нишләтәсең, кешенең табигате шундый. Авыр көннәремдә мин тамашачымның үземә бик кирәклеген аңладым. Рәхмәт сезгә!

Чынлап та, тамашачы Зөлфәт абыйның җырларын тыңларга сусаган. Залда ияреп җырлаучылар да юк түгел. 1980–1990 нчы елларда популяр булган җырларның бүген дә үз тыңлаучысы бар. Ә җырларының барысы да күңелгә керә торган. Йөрәктән чыкканга шулай ул. Күпме җырын тыңлап та, бер генә мәгънәсез сүз очрамады. Шулкадәр тормышның үзенә, бүгенге хис-кичерешләргә туры килә торган алар.

Зөлфәт абыйның концертында татар эстрадасының иң зәвыклы, моңлы җырчылары җыелган иде. Ул аларны үзе сайлап алган. Иң беренчеләрдән булып сәхнәгә Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Винера Ганиева чыкты.

– Зөлфәтнең җырлары матур аның. Әмма ул аларны кешегә бирми. Күңел халәтемә туры килгәнен көчкә сорап алдым, – диде җырчы.

Татарстанның атказанган артисты Алинә Шәрипҗанова да Зөлфәт Хәкимнең җырларын башкарды. Сәхнәгә шушы ике җырчы чыгу да аны моңга күмде. Яшь җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗановага Зөлфәт абый атап шигырь дә язган әле. Сокלануын яшерми ул аңа. Яшерерлек тә түгел. Кечкенә генә кызның кай җиреннән чыгадыр ул шулкадәр моң? Тамашачы аны бик яратып кабул итте. Кечкенәдән Зөлфәт җырларында үскән Мәксүт Юлдашевның җырлары да бик ошады.

Концерт уйландырды. Зөлфәт абый да яшәү, мизгел, гомер, үлем кебек төшенчәләр тирәсендә бөтерелде. Җырларның күбесе шул темага. Әнә Германия хастаханәсендә язганы бөтенләй күңелне айкый. Җырлар дигәннән, «Нәрсә булды сиңа бүген...» дигәнен миңа бир дип сораучылар шактый икән. Әмма Зөлфәт абый ашыкмый. Ул аны кешегә бирергә теләми.

– Мин бу җырны яшисе килмәгән вакытта, дөньядан ваз кичеп, каядыр качарга теләгәндә яздым. Тиздән аңа 40 ел була. Еллар узган саен, ул җырны ныграк сорыйлар, – ди ул. – Тормышта сатылмый торган әйберләр бар. Әйтик, мизгел, вакыт, сәламәтлек. Аларның бәясе юк. Бу җырымның бәясе юк. Ул үземнеке генә. Шуңа да кешегә бирергә теләмим.

Зөлфәт Хәким беркайчан да акча өчен яшәмәгән. Хәтта заманында аның җырларын иң беренче булып дискка яздырып бирәләр. Ул моны берәүдән дә үзе сорамый. Берәр ел узгач, без сезнең җырларны яздырткан идек, менә гонорары дип, үзенә 50 данә диск бүләк итәләр.

Әлеге концертны «Барс медиа» компаниясе оештырган. Аны Татарстанның атказанган артисты Гөлназ Сәфәрова алып барды. Сценарий авторы да ул икән. Гөлназ сәхнәгә чыккач та, янәшәмдәге тамашачы: «Сәфәрова булган җирдә затлылык инде», – дип куйды. Сүзләрендә хаклык бар. Концертның ардырмыйча, бер сулышта узып китүендә Гөлназның роле зур. Зөлфәт Хәким аңа бик рәхмәтле.

– Аның кебек ипле алып баручы юк. Ул – бердәнбер. Әгәр концерт җылы үтә икән, монда алып баручының роле зур. Мин Гөлназны бик хөрмәт итәм, – диде.

Еллар узса да, Зөлфәт Хәким җырлары искерми. Рәхәт кич булды ул. Менә нинди була ул затлы җырчы! Аның көчле рухы да сокландырды. Башкалар әйтергә курыккан диагноз белән ул инде икенче тапкыр «Сәйдәш» мәдәният йортын тутырып концерт куя. Күпме җыр башкара. Шушы көннәрдә янә дәваланырга чит илгә китә икән. Бер генә теләк – көчле рухы авыруын җиңсен иде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 341

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+